***Муниципаль тур***

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕНЕҢ
**ҖАВАПЛАРЫ**
(2025-2026 нчы уку елы)
**7 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 150 минут**
**Максималь балл – 60**

**I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.**

1. Җөмләдәге иренләшкән сузык авазларның санын билгеләгез. **(2 балл)**
*Коега төкермә, суын үзең эчәрсең.* (Мәкаль)
а) 2
ә) 4
б) 5
**в) 6**

2. Ирен ассимиляциясе күзәтелгән сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
а) урман
ә) сөлге
**б) унбиш**
в) урманнар

3. Җөмләдәге басымы соңгы иҗеккә төшмәгән сүзләрнең барысы да күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**
*Кайда су чыкса, коены шунда казыйлар.* (Мәкаль)
а) кайда
ә) казыйлар
**б) кайда, казыйлар**
в) кайда, шунда, казыйлар

4. Фразеологизмның мәгънәсен билгеләгез. **(2 балл)**
***коры елгага батыру***
**а) алдалау**
ә) ачулану
б) тавышлану
в) көлү

5. ***Зәңгәр*** сүзе күчерелмә мәгънәдә кулланылган рәтне билгеләгез. **(2 балл)**
а) зәңгәр күлмәк
ә) зәңгәр һава
б) зәңгәр чәчәк
**в) зәңгәр хыял**

6. Тамырдаш булмаган сүзләрне билгеләгез. **(2 балл)**
а) юлдаш, юлчы
ә) башлы, башлык
б) аклык, аклама
**в) беләң, белде**

7. Билгесезлек алмашлыгын билгеләгез. **(2 балл)**

а) минеке

ә) шул

**б) кемдер**

в) беркем

8. Чикләүне белдерә торган кисәкчәне билгеләгез. **(2 балл)**

**а) гына**

ә) ич

б) түгел

в) дөм

9. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзнең нинди җөмлә кисәге икәнлеген билгеләгез. **(2 балл)**

*Тирән күлдә балык та* ***күбрәк.*** (Мәкаль)

а) ия

**ә) хәбәр**

б) күләм хәле

в) аергыч

10. Инкяр җөмләне билгеләгез. **(2 балл)**

а) Суның кадере чишмә корыгач беленә. (Мәкаль)

ә) Тамчыдан күл җыела. (Мәкаль)

б) Суга батучы саламга да ябыша. (Мәкаль)

**в) Суда балык адашмас. (Мәкаль)**

## II. Теоретик бирем.

Сызыклар өстенә тиешле сүзләрне языгыз. **(6 балл)**

Бер иҗекле сүзләргә басым тамгасы куелмый. Һәр иҗектә бер сузык аваз була. Телнең лексик составын өйрәнә торган фән – лексикология. Тамыр һәм сүз ясагыч кушымча – сүзнең нигезе. Инфинитив – затланышсыз фигыль. Тиңдәш кисәкләр арасына өтер яисә сызык куела ала.

## III. Башыгызны эшләтегез.

Парлы сүзләрнең беренче компонентларын уйлап языгыз. **(4 балл)**

иге-чиге

вак-төяк

аң-белем

кирәк-ярак

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Җөмләләрне татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(6 балл)**

Трава пожелтела и завяла. Птицы тронулись на юг. Их гонят холод и голод.

2. Шигырьне укыгыз һәм биремнәрне эшләгез.

Ямансу көзләр җитә. Урманга сары ут каба.
Яфраклар җансыз кошлар күк оча һавада.
Бакчада былбыл тына. Тып-тын яңгырлар ява.

(*Акъегет*)

2.1. Яңгыраулыкта охшашлану күзәтелгән сүзне күчереп языгыз. **(1 балл) (урманга)** (артык сүз язылса, балл киметелә!)
2.2. Кече тел арты ассимиляциясе күзәтелгән сүзне күчереп языгыз. **(1 балл) (урманга)** (артык сүз язылса, балл киметелә!)
2.3. Тартыклар чиратлашуы күзәтелгән сүзне күчереп языгыз. **(1 балл) (каба)** (артык сүз язылса, балл киметелә!)
2.4. ***Былбыл*** сүзнең синонимын языгыз. **(1 балл) (сандугач)**
2.5. ***Тып-тын*** сүзенә морфологик-синтаксик анализ ясагыз. **(3 балл)**
***Тып-тын* – сыйфат, артыклык дәрәҗәсендә, тамыр сүз, җөмләдә хәл.**
2.6. Бирелгән җөмләгә синтаксик анализ ясагыз (җөмлә кисәкләренең асларына сызыгыз, төрләрен билгеләгез, җөмләгә билгеләмә языгыз). **(5 балл)**
Яфраклар(г.и.) җансыз кошлар күк(р.х.) оча(г.ф.х.) һавада(у.х.). Бу – раслау, хикәя, җәенке, тулы, гади җөмлә.

3. **«Быелгы көз»** дигән темага 8-10 җөмләдән торган инша языгыз. **(12 балл)**